

Бәйрәмдә vзәк урынны һонәрчеләр-дән kvргәзмәләр һәм мастер-класслар алып торды. Сәнгатьнен тvбәндәге торләре тәкъдим ителде: рәсем - рәсем сәнгате, графика; скульптура - таш, агач; декоратив-гамәли сәнгать - чигv, чәкән; агачка рәсем ясау, тукымаларга рәсем ясау, токарь эшләнмәләре ясау; керамика, тvгәрәкләv, чигv, буяу эшкәртv, чvлмәк ясау сәнгате. Биредә шулай ук сувенирлар ярминкәсе дә булды. «Вирень-арт» та гастрономия мәйданчыклары эшләде, анда те-ләгән һәркем рус, татар, мордва ха-лыкларынын торле продуктлары һәм ашамлыклары сатып алырга була иде. «Әдәби кайнатмалар» - гастрономия тамашасы элементлары белән агарту-культурологик проект та кызыклы булды.      Фестиваль кунаклары мордва халкы йолаларында катнаша алдылар. Биредә  янгыр сорау турында театральләштерелгән уен vткәрелде. Урман фестивалендә ин яшь катнашучылар очен балалар мәйданчыгы эшләде. Анда хәрәкәтле уеннар, танып-белv викториналары vткәрелде. Рәсем сәнгатен балалар аквагрим ярдәмендә vзләштерделәр.
Топ сәхнәдә музыкаль коллективлар чыгыш ясады. Тамашачыларга Темниково Мәдәният сарае артистлары, «Родники», «Ивушки» халык ансамбльләре чыгышлары истә калды. Ельник районы Каньгушан авылы мәдәният йортынын «Мокшаваня» халык фольклор ансамбле кунакларга мордва музыка сәнгатенен vзенчәлекле бер чиген kvрсәтте. Саранскидан «Жива» ансамбле дә кунакларны соендерде. Концерт программасын Ширингуши һәм Краснослободский мәктәп-интернатларында тәрбияләнvчеләр хуплады. Фестиваль осталарынын мәйдан-чыклары шулай ук «Мордовия заповеднигы табышмаклары» дигән квест станцияләре дә булды. Ин житез һәм тапкырлылар истәлекле сувенирлар алдылар. Билетлар буенча призлар уйнатылды. Kvпләр фестиваль осталарыннан уникаль бvләкләр алды.
«Вирень-арт» катнашучылары һәм кунаклары фестиваль мәйданчык-ларында гына тvгел, ә Мордовия заповеднигынын экскурсия объектларында да булдылар: «Таныш булыгыз: Мордовия заповеднигы!», «Бабалар сукмагы» мифологик маршруты һәм табигать музее.

**Н.Хәлил**